МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ____328/о______

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«__24___»______03________2025__

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан «Кадастр номерлары 16:27:040401:1342, 16:27:040401: 1344, 16:27:040401:1386 булган участоклар чикләрендә яңа координаталар буенча линия объектын күчерү юлы белән «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ участогын реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру проектын һәм территориясен ызанлау проектын раслау турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45 һәм 46 статьялары, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан «Кадастр номерлары 16:27:040401:1342, 16:27:040401: 1344, 16:27:040401:1386 булган участоклар чикләрендә яңа координаталар буенча линия объектын күчерү юлы белән «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ участогын реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру проектын һәм территориясен ызанлау проектын әзерләү турында» 2024 елның 9 декабрендәге 699/о номерлы боерыгы нигезендә, 2025 елның 16 гыйнварында үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан «Кадастр номерлары 16:27:040401:1342, 16:27:040401: 1344, 16:27:040401:1386 булган участоклар чикләрендә яңа координаталар буенча линия объектын күчерү юлы белән «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ участогын реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру проектын һәм территориясен ызанлау проектын расларга (кушымтада бирелгән).

2. Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү

идарәсенең Кама агломерациясен үстерү бүлегенә (В.В.Бельскийга) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгына һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Менделеевск шәһәре башлыгына ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып җиде эш көне эчендә урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Отдел контроля исполнения документов

Министр урынбасары В.Н.Кудряшев

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министрлыгының
24.03.2025 ел, №328/о боерыгы белән
расланды

# Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан «Кадастр номерлары 16:27:040401:1342, 16:27:040401: 1344, 16:27:040401:1386 булган участоклар чикләрендә яңа координаталар буенча линия объектын күчерү юлы белән «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ участогын реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру проекты

# ТЕРРИТОРИЯНЕ ПЛАНЛАШТЫРУ ПРОЕКТЫ

«Кадастр номерлары 16:27:040401:1342, 16:27:040401: 1344, 16:27:040401:1386 булган участоклар чикләрендә яңа координаталар буенча линия объектын күчерү юлы белән «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ участогын реконструкцияләү» объекты буенча линия объектларын урнаштыру өчен

1 нче бүлек «Территорияне планлаштыру проекты. График өлеше»

ППТ/ОЧ/ГЧ

**2025 ел**

| Том № | Билгеләнеше | Атамасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | ППТ/ОЧ/ГЧ | 1 нче бүлек. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеше | |
| 2 | ППТ/ОЧ/ТЧ | 2 нче бүлек. Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә | Китерелми |
| 3 | ППТ/МО/ГЧ | 3 нче бүлек. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү буенча материаллар. График өлеше | Китерелми |
| 4 | ППТ/МО/ПЗ | 4 нче бүлек. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү буенча материаллар. Аңлатма язуы | Китерелми |
| 5 | ПМТ/ОЧ/ГЧ | 1 бүлек. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше | |
| б | ПМТ/ОЧ/ТЧ | 2 нче бүлек. Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше. | Китерелми |
| 7 | ПМТ/МО/ГЧ | 3 нче бүлек. Нигезләү материаллары. График өлеше | |
| 8 | ПМТ/МО/ПЗ | 4 нче бүлек. Нигезләү материаллары. Аңлатма язуы | |

| Үзг. | Кишәсаны | Бит | док.№ | Имза | Дата |
|---|---|---|---|---|---|
| ГИП | | Бурсаков | | | 07.24 |
| Н. Контр. | | Стешин | | | 07.24 |
| Эшләде. | | Исламов | | | 07.24 |

ППТ/ОЧ/ГЧ

Проект составы

«Геоконсалтинг» ҖЧҖ

# ЭЧТӘЛЕК

1. Проект составы 2

2. Кызыл линияләр сызымы 4

3. Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең сызымы 5

4. Урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең сызымы 8

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының планировка проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территориядә кызыл линияләрнең булуы/булмавы турында 09.07.2024 ел, № 2157 хаты нигезендә (элек Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән) кызыл линияләр юк. Проектта кызыл линияләрне билгеләү һәм / яки гамәлдән чыгару күздә тотылмый, шуңа бәйле рәвештә кызыл линияләр сызымы эшләнми.




## Махсус билгеләр

1- - - - 1 аңа карата планлаштыру проекты әзерләнә торган территория чикләре
- линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләре

• 1 линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары номерлары, шул исәптән башлану һәм тәмамлану нокталары, мондый зоналар чикләре тасвирламасын үзгәртү нокталары

Искәрмә:
1. Линия объекты составында проектлана торган капиталь төзелеш объектлары проектта каралмаган.

ППТ/ОЧ/ГЧ

«Кадастр номерлары 16:27:040401:1342, 16:27:040401: 1344, 16:27:040401:1386 булган участоклар чикләрендә яки координаталар буенча линия объектын күчерү юлы белән «Щелоков Аммоний» ЛЭП-110 кВ участогын реконструкцияләү» объекты

| Должность | Ф.И.О. | Подпись |
|---|---|---|
| ГИП | Бурсаков | |

Бүлек җит.

Территорияне планлаштыру проекты

Стадия Бит Битләр ППТ 3

Планлаштырыла торган линия объектларын урнаштыру зонасы чикләре сызымы



**ТЕРРИТОРИЯНЕ ПЛАНЛАШТЫРУ ПРОЕКТЫ**

«Кадастр номерлары 16:27:040401:1342, 16:27:040401: 1344, 16:27:040401:1386 булган участоклар чикләрендә яңа координаталар буенча линия объектын күчерү юлы белән «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ участогын реконструкцияләү» объекты буенча линия объектларын урнаштыру өчен

2 нче бүлек «Территорияне планлаштыру проекты. Текст өлеше»

ППТ/ОЧ/ТЧ

**2025 ел**

| Том номеры | Билгеләнеше | Атамасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | ППТ/ОЧ/ГЧ | 1 нче бүлек. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеше | |
| 2 | ППТ/ОЧ/ТЧ | 2 нче бүлек. Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә | Китерелми |
| 3 | ППТ/МО/ГЧ | 3 нче бүлек. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү буенча материаллар. График өлеше | Китерелми |
| 4 | ППТ/МО/ПЗ | 4 нчы бүлек. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү буенча материаллар. Аңлатма язуы | |
| 5 | ПМТ/ОЧ/ГЧ | 1 бүлек. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше | Китерелми |
| б | ПМТ/ОЧ/ТЧ | 2 нче бүлек. Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше. | Китерелми |
| 7 | ПМТ/МО/ГЧ | 3 нче бүлек. Нигезләү материаллары. График өлеше | |
| 8 | ПМТ/МО/ПЗ | 4 нчы бүлек. Нигезләү материаллары. Аңлатма язуы | |

| Үзг. | Кит.саны. | док.№ | Имза | Дата |
|---|---|---|---|---|
| ГИП | Бурсаков | | | 07.24 |
| Н. Контр. | Стешин | | | 07,24 |
| Эшләде. | Исламов | | | 07.24 |

ППТ/ОЧ/ТЧ

**Стадия 1** Бит Битләр

Проект составы

ЖЧЖ «Геоконса11тинг»

**Эчтәлек**


1. Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә планлаштырыла торган линия объектларының, шулай ук реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының исеме, төп характеристикалары (озынлыгы, проект куәте) һәм билгеләнеше ........................................4

2. Территорияләрендә линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге шәһәрләрнең җирлекләре, торак пунктлары, шәһәр эчендәге территорияләре исемлеге ......5

3. Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге ......................................................................................................5

4. Урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге ......................................................................................................................6

5. Планлаштырылган урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керүче капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары....................................................................................................................... 6

6. Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелә торган капиталь төзелешнең сакланып калучы объектларын (бинаны, төзелешне, корылманы, төзелеп бетмәгән объектларны), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документация нигезендә төзүгә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат………………………………………………………6

7. Линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклап калу чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат……….........................................................................................................………...7

8. Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат …….7

9. Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат ............................................................................ 16


| Изм | Бит | Доку. № | Имза | Дата | ППТ/ОЧ/ТЧ | Бит 3 |
|---|---|---|---|---|---|---|

**1. Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының исеме, төп характеристикалары (озынлыгы, проект куәте) һәм билгеләнеше**

Территорияне планлаштыру проекты «Кадастр номерлары 16:27:040401:1342, 16:27:040401: 1344, 16:27:040401:1386 булган участоклар чикләрендә яңа координаталар буенча линия объектын күчерү юлы белән «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ участогын реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру проектын һәм территориясен ызанлау проектын әзерләүгә техник йөкләмә нигезендә эшләнде.

Объектның исеме - «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ».

Әлеге проектта Кадастр номерлары 16:27:040401:1342, 16:27:040401:1344, 16:27:040401:1386 булган участоклар чикләрендә яңа координаталар буенча линия объектын күчерү юлы белән «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ оештыру буенча техник чишелешләр эшләнгән.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, гамәлдә булу срокларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә, эксплуатациягә кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында» 02.04.2022 ел, № 575 карарының 4 пункты нигезендә, территорияне планлаштыру буенча линия объектын урнаштыруны күздә тота торган документация әзерләү һәм раслау, әгәр мондый линия объектын урнаштыру территориаль планлаштыру документларында каралмаган булса, федераль һәм региональ әһәмияттәге линия объектларына карата рөхсәт ителә.

Планлаштырыла торган линия объектының якынча озынлыгы 1 245 м тәшкил итә.

Территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын эшләү өчен якынча мәйдан 2,1 гектар тәшкил итә.

РФ Хөкүмәтенең «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын билгеләү тәртибе һәм җир участокларыннан файдаланунын махсус шартлары турында» 24.02.2009 ел, №160 карары нигезендә «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ» кабель участогының саклау зонасы якынча 2 метр тәшкил итәчәк (кырый кабельләрдән электр тапшыру линиясенең ике ягына да 1әр метр). «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ» һава участогыннан якынча 50 метр тәшкил итәчәк (кырый чыбыклардан электр тапшыру линиясенең ике ягына да 20шәр метр).

Реконструкция максатларында 20 нче терәктән 25 нче терәккә кадәр «Щелоков Аммоний» ЛЭП-11О кВ» участогын кабельгә күчерү башкарыла.

Проектта урыннары үзгәрү сәбәпле реконструкцияләнергә тиешле линия объектлары каралмаган.

## 2. Территорияләрендә линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге шәһәрләрнең җирлекләре, торак пунктлары, шәһәр эчендәге территорияләре исемлеге

Административ-территориаль яктан линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» МБ чикләрендә урнашкан.

## 3. Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге

3.1 нче таблица Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләре

| Характерлы нокта номеры | Координаталар (МСК 16-2) | | Характерлы нокта номеры | Координаталар (МСК 16-2) | |
|---|---|---|---|---|---|
| | X | У | | X | У |
| 1 | 486700.81 | 2304256.06 | 8 | 486799.95 | 2304188.84 |
| 2 | 486706.65 | 2304264.55 | 9 | 486801.95 | 2304188.77 |
| 3 | 486783.08 | 2304195.19 | 10 | 486803.99 | 2304199.64 |
| 4 | 486784.41 | 2304197.12 | 11 | 487104.00 | 2304277.75 |
| 5 | 486791.40 | 2304207.30 | 12 | 487105.33 | 2304267.77 |
| 6 | 486791.85 | 2304207.97 | 13 | 487107.06 | 2304277.78 |
| 7 | 486797.51 | 2304185.29 | 14 | 487108.39 | 2304267.80 |

| Характерлы нокта номеры | Координаталар (МСК 16-2) | |
|---|---|---|
| | X | У |
| 15 | 487111.65 | 2304278.98 |
| 16 | 487114.34 | 2304280.44 |
| 17 | 487115.36 | 2304269.61 |
| 18 | 487118.04 | 2304271.08 |
| 19 | 487392.44 | 2304352.85 |
| 20 | 487393.77 | 2304342.87 |
| 21 | 487396.83 | 2304342.90 |
| 22 | 487400.09 | 2304354.08 |
| 23 | 487402.77 | 2304355.55 |
| 24 | 487403.79 | 2304344.71 |

| Характерлы нокта номеры | Координаталар (МСК 16-2) | |
|---|---|---|
| | X | У |
| 25 | 487406.48 | 2304346.18 |
| 26 | 487746.60 | 2304445.07 |
| 27 | 487752.45 | 2304436.26 |
| 28 | 487762.49 | 2304470.21 |
| 29 | 487765.01 | 2304469.09 |
| 30 | 487770.31 | 2304487.85 |
| 31 | 487774.41 | 2304464.92 |

**4 Линия объектларының урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге**

Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге аларның урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле объектлар кирәк булмауга бәйле рәвештә эшләнми.

**5. Планлаштырыла торган урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керүче капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары**

Планлаштыру проектын эшләү чикләрендә линия объекты составында проектлана торган капиталь төзелеш объектлары юк шуңа бәйле рәвештә планлаштырыла торган зоналар чикләрендә линия объектлары составына керә торган капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары билгеләнми.

**6. Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелә торган капиталь төзелешнең сакланып калучы объектларын (бинаны, төзелешне, корылманы, төзелеп бетмәгән объектларны), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документация нигезендә төзүгә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Планлаштыру проекты эшләнә торган территория чикләрендә җир асты һәм җир өсте инженерлык коммуникацияләре урнашкан. Әлеге проект нигезендә планлаштырыла торган объектларның гамәлдәге инженерлык инфраструктурасы объектларына тискәре йогынтысы планлаштырыла торган объектларны төзү чорында мөмкин. Объектларны штат режимында эксплуатацияләү чорында объектларны проектлау территориясе чикләрендәге объектларга тискәре йогынты ясалмый. Планлаштырыла торган объектларны проектлауның алдагы стадияләрендә капиталь төзелешнең сакланып калучы объектларын линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә тискәре йогынтыдан яклау чараларын күздә тотарга кирәк.

## 7. Линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклап калу чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

ТР Менделеевск МР советының 07.07.2016 ел, №67 карары белән расланган ТР Менделеевск МР территориаль планлаштыру схемасы, ТР Менделеевск МР советының 28.12.2018 ел, №71 карары белән расланган «Менделеевск шәһәре» МБ генераль планы, 04.09.2024 ел, №14рт-24 дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза акты һәм Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 17.09.2024 ел, № О1-04/5258 бәяләмәсе нигезендә, планировкалау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территориядә җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре һәм башка эшләр йогынтысына дучар булган җир кишәрлекләрендә мәдәни мирас объектлары яисә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектлар исәпләнми.

## 8. Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Янәшәдәге территорияләргә төп тискәре йөкләнеш төзелеш эшләрен башкару чорына туры килә. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты булырга мөмкин, ул атмосфера һавасының пычрануы, тавыш дәрәҗәсенең күтәрелүе, грунт һәм җир өсте суларының пычрануы, төзелеш машиналары һәм механизмнары эшләгәндә яшел утыртмаларның зарарлануы белән чагыла.

Чыгарылмалар составында өстенлекле пычраткыч матдәләр булып үлчәүле матдәләр, ягъни комлы һәм балчыклы грунтлардан тузан, органик кушылмалар, транспорт чаралары чыгарылмалары составына керүче азот оксиды, углерод, күкерт кушылмалары, күчеп йөрүче грунтлардан икенчел пычрану тора.

ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 12.07.2024 ел, № 12675/12 хаты нигезендә, Министрлыкның геологик мәгълүмат фондында булган мәгълүматларга караганда, сорала торган кишәрлектә Татарстан Республикасының эзләп табылган һәм территориаль казылма байлыклары запаслары балансында исәпләнгән гомуми файдаланыла торган файдалы казылмалар ятмалары юк. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензияләр бирелмәгән. Файдалануга бирү планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре юк. Расланган запаслары тәүлегенә 500 м3 артмаган җир асты сулары ятмалары юк. Татарстан Республикасы буенча җир асты байлыкларыннан (җир асты суларыннан) файдалануга лицензияләр реестрында тәүлегенә 500 м3 артык булмаган су җыю лицензияләре исәпләнми. Халыкны хуҗалык-эчәр су белән тәэмин итү максатыннан су алу өчен өске су объектлары Министрлык тарафыннан файдалануга тапшырылмаган. Сорала торган участок чикләрендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итүнең расланган санитар-саклык зоналары проектлары һәм санитар-саклык зоналары билгеләгән су чыганаклары юк.

Төзелешне оештыру проектында экологик чаралар комплексы каралган, аны тайпылышсыз үтәгәндә объект төзелешенең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысы минималь һәм мөмкин булган йогынты буларак бәяләнә.

1. Эшләр бары тик билгеләнгән стройда гына башкарылырга тиеш. Ген.планда эшләр зонасы махсус койма белән әйләндереп алынырга тиеш. Эшләр зонасы яшеллекләрнең һәм гамәлдәге җир өсте һәм җир асты корылмаларының максималь саклануын исәпкә алып билгеләнгән. Эшләр зонасы мәгълүмат щитлары урнаштырылган челтәрле киртә белән әйләндереп алынырга тиеш.

2. Эшләр машина һәм механизмнарның кирәкле куәте булганда техник чараларның минималь күләмендә башкарыла, бу тавыш, тузан, вибрация һәм һаваны пычрату күләмен киметү өчен кирәк.

3. Янәшәдәге урамнарга һәм яшеллеккә, шулай ук төзелеш мәйданчыгына керү юлларына су сибү-юдырту машинасы каралган. Тәгәрмәчләрне юу өчен «C-TECH WWHl 508» тибындагы йомык циклны су әйләнеше юу урыны каралган. Төзелеш машиналары һәм механизмнары гамәлдәге автомобиль юллары буйлап, шулай ук эшче сызымнарда күрсәтелгән чикләрдә вакытлыча керү юллары буйлап йөрү каралган.

4. Машиналарга һәм механизмнарга ягулык салу торак пунктларның ягулык салу станцияләрендә яки ягулык салучылардан «пистолет» кулланып башкарыла, бу ягулыкның җиргә әләгүен чикли.

5. Машина һәм механизмнарны төнгә кую махсус җиһазландырылган мәйданчыкларда каралган.

6. Биобәдрәфләрнең эчлеге вакыт-вакыт суыртыла һәм махсус автотранспорт белән санэпидемстанция күрсәткән урыннарга озатыла.

7. Хуҗалык-эчү ихтыяҗлары өчен су торак пунктларның челтәрләреннән һәм чыганакларыннан китерелә, ә бу аны табигый сулыклардан алуны чикли.

8. чоңгылсыз грунт һәм вак ташны төзелеш зонасындагы карьерлардан һәм предприятиеләрдән алу планлаштырылган.

9. Чүп-чар һәм төзелеш материаллары калдыклары өчен тупланма бункер каралган.

10. Сибелүчән һәм сыек материалларны тәртип белән транспортировкалау һәм җыю тәэмин итәлергә тиеш. Коелучан материалларны төзелеш мәйданчыгыннан читкә ташыганда машина кузовлары махсус тентлар белән капланырга тиеш.

11. Төзелеш мәйданчыгы территориясендә учак ягу, ачык казаннарда битум пешерү тыела

12. Эшкәртелгән майны грунтка агызу тыела.

14. Тимер-бетон эшләнмәләрне, конструкцияләрне һәм материалларны җыю махсус мәйданчыклар территориясендә башкарылачак, монтаж «тәгәрмәчләрдән» башкарылырга мөмкин.

15. Эшләр тәмамлангач, эш зонасы бетереләчәк, чүп-чар, материаллар җыештырылачак, киртәләрне сүтү башкарылачак.

16. Туфрак әзерләп, үсемлек катламы өстәп һәм үлән чәчеп, газоннарны торгызу эшләре башкарыла (эш зонасы чикләрендә), яшел утыртмаларны торгызу юлы белән территорияне төзекләндерү каралган.

17. Агым суларны чистарту махсус отстойникта каралган, анда үлчәүдәге кисәкчекләр отстойник төбенә утыра, ә чиста су рельефка чыгарыла. Алдан чистартылган агып төшүче суларны подряд оешмасы гамәлдәге яңгыр канализациясенә «Водоканал» ДУП белән төзелгән килешү нигезендә агызырга тиеш.

18. Яшел утыртмалары булган кишәрлектә эшләр башкарганда аларны саклау чаралары башкарылырга тиеш. Яшел утыртмаларны кисү бары тик яшел утыртмаларны саклау буенча махсус вәкаләтле орган белән килешү буенча гына рөхсәт ителә. Киселергә тиеш булмаган яшел үсентеләр төзелеш мәйданчыгында койма белән әйләндереп алынырга тиеш. Эш башкару зонасына эләгүче аерым агачларның кәүсәләре кимендә 2 метр биеклеккә агач материаллары белән тышлау юлы белән зарарланудан сакланырга тиеш;

19. Эшләр башкарылган зона янындагы сулыкларда суның даими дәрәҗәсе коелар һәм торбалар аша су агызу системасы хисабына тәэмин ителә. Шулай итеп, төзелеш территориясен су басу һәм, нәтиҗәдә, сулыкларны пычрату ихтималы юк ителә. Сулыкларның тугай өлеше эшләр башкарганда кагылгысыз кала.

***Атмосферага чыгарыла торган матдәләрне киметү гамәлләре***

Атмосфера һавасына йогынтыны киметү өчен түбәндәге чараларны үтәүне күздә тотарга кирәк:

- төзелеш машиналары һәм механизмнары эше эшкәртелгән газ чыгаруның мөмкин булган минималь күләменә һәм тавыш дәрәҗәсенә көйләнгән булырга тиеш;

- теләсә кайсы вакытта эшли торган двигательләр белән төзелеш технологиясендә катнашмаган техниканы калдыруны тыю,
- бушка йөрүне чикләү;
- -бер үк вакытта эшли торган юл һәм төзелеш техникасы санын мөмкин кадәр киметү;
- җитештерү технологияләрен катгый үтәү;
- эшкәртелгән газларның агулылыгын һәм төтенлелеген контрольдә тоту;
- ягулык, тукландыру һәм кабызу системаларын вакытында ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү һәм җайга салу;
- двигательләрне җылыту һәм эшләтеп җибәрүне җиңеләйтү җайланмаларын куллану;
- техник карау үткәрү һәм хәрәкәт итүче составның агулылыгын һәм төтенлелеген контрольдә тоту срокларын катгый үтәү;
- кулланыла торган ягулык һәм майлар стандартлар яисә техник шартлар таләпләренә туры килергә тиеш;
- төзек булмаган яисә көйләнмәгән двигательле һәм ягулык стандартларына туры килми торган техниканы эксплуатацияләүне тыю;
- материалларны туплау зонасын өч яктан койма белән әйләндереп алырга, лапас ясарга;
- тузансыман материалларны һәм калдыкларны (грунт, ком) вакыт-вакыт су белән чылатырга, бу исә әлеге калдыкларның һәм материалларның җил белән таралуын булдырмауны гарантияли;
- теләсә нинди калдыкларны яндыруны тыю.
-

***Калдыкларны чыгару һәм утильләштерү чишелешләренең тасвирламасы***

Демонтаж эшләрен башкару барышында барлык конструкцияләр, элементлар «Возрождение» каты көнкүреш калдыклары полигонына озатыла. Эшләр башкарылган урыннан 20 км ераклыкта урнашкан.

Демонтаж эшләрен башкару урыны торак йортлар янында урнашу сәбәпле, демонтажланган конструкцияләрне һәм элементларны җыю урыннарын өем белән җитештермәскә. Демонтажлана торган барлык конструкцияләрне шунда ук утильләштерүгә чыгарырга кирәк.

Калдыкларны вакытлыча туплау СанПиН 2.1.3684-21 «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчә торган суга һәм эчә торган су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак урыннарга, җитештерү, җәмәгать урыннарын эксплуатацияләүгә, санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны оештыруга һәм үткәрүгә санитар-эпидемиологик таләпләр»гә туры килергә тиеш.

Төзелеш калдыкларын, демонтаж эшләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән чүп-чарны контейнерларга салып, көнкүреш калдыкларын саклау һәм эшкәртү өчен полигонга чыгарырга кирәк. Контейнерлар тулган саен шунда ук чыгарылырга тиеш. Төзелеш мәйданчыгында калдыкларны һәм чүп-чарны яндыру тыела.

Төзелеш эшләре вакытында барлыкка килә торган калдыклар белән эш итү төзелеш буенча подряд оешмасы көче белән гамәлгә ашырыла, ул эшләрне башлаганчы I-IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны җыю, транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган махсуслаштырылган оешмалар белән калдыкларны җыю, транспортлау һәм тапшыру буенча шартнамәләр төзергә тиеш.

Тыела:

- автотранспорт хәрәкәте вакытында территориянең чүпләнүе;
- автотранспортның техник системаларыннан май һәм башка ягулык-майлау материаллары агызу;
- автотранспортның газоннар һәм башка утыртмалар буйлап йөрүе.

***Җир кишәрлеген рекультивацияләү һәм төзекләндерү чаралары исемлеге (кирәк булганда)***

Җир кишәрлеген төзекләндерү туфрак-үсемлек катламын торгызу юлы белән күз алдында тотыла.

***Җир өсте һәм җир асты суларын саклау гамәлләре***

Төзелеш чорында җир өсте һәм җир асты суларын саклау максатларында түбәндәге чараларны күздә тотарга кирәк:

- өске суларның агып төшүен өске су агызу системасын төзү һәм вертикаль планлаштыру ярдәмендә җайга салу;

| Үзг. | Бит | Док. № | Имза | Дата | ППТ/ОЧ/ТЧ | -- |
|---|---|---|---|---|---|---|

- җир асты конструкцияләрен гидроизоляцияләү;
- җир асты конструкцияләрен сәнәгать агынтыларының агрессив йогынтысыннан саклау өчен коррозиягә каршы чаралар;
- вакытлы складларны, грунтовка, лак-буяу материаллары, битум, бензин һ.б. эләкмәсен өчен, су объектының яр буе полосасыннан һәм су саклау зонасыннан читтә урнаштыру;
- бу максатлар өчен каралмаган урыннарда машиналарны һәм механизмнарны юуны һәм ремонтлауны булдырмау;
- ягулык-майлау материалларын махсус билгеләнгән урыннарга агызып, соңыннан утильләштерү һәм чистарту; төзелеш мәйданчыгында ягулыкны саклауны булдырмау;
- көнкүреш, хуҗалык һәм ярдәмче биналарны яр буе полосасыннан һәм су саклау зонасыннан читтә урнаштыру
- җир өсте һәм җир асты суларын пычрату мөмкинлеген бетерә торган җитештерү һәм көнкүреш агынтыларын җыюны һәм агызуны оештыру;
- эш урыннарын һәм вакытлы урыннарны көнкүреш һәм төзелеш калдыклары өчен инвентарь контейнерлар белән тәэмин итү.

***Туфрак катламына йогынты дәрәҗәсен киметү чаралары***

Җирләрне саклау түбәндәге проект чишелешләре белән тәэмин ителергә тиеш:

- җирләрдән нәтиҗәле файдалану,
- корылмаларны төзелеш тыгызлыгы нормативларын үтәп, минималь кирәкле мәйданнарда һәм, мөмкин булганча, авыл хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен яраксыз аз кыйммәтле җирләрдә урнаштыру;
- кыр һәм авыл юллары буйлап гамәлдәге коридорлар буйлап линия корылмалары салу (канализация, ВЛ);
- җитештерү һәм куллану калдыкларын полигонга чыгару өчен махсус контейнерларга җыю;
- ачык ут белән эш алып баруны, учак ягуны тыю;

- үсемлекләр капламының зарарлануын булдырмау һәм туфракны җимерү йогынтысын минимальләштерү таләпләрен исәпкә алып, вакытлыча автомобиль һәм башка керү юлларын төзү;

- пычраткычларны тулырак җыю мөмкинлеген исәпкә алып, җирлекнең түбән участокларында дренаж урнаштыру;

- проектта каралмаган метларда төзелеш-монтаж эшләрен башкаруны, машиналар һәм механизмнар хәрәкәтен тыю;

- проект документациясендә каралмаган урыннарда материалларны туплауны һәм саклауны тыю;

- барлык төзелеш-монтаж эшләрен башкару бары тик бүленгән полоса чикләрендә генә гамәлгә ашырыла. Проектлаганда түбәндәгеләрне күздә тотарга:

- төзелеш объектлары санын һәм мәйданын мөмкин кадәр киметү;

- объектларны урнаштыруны оптимальләштерү;

- табигый суларның, һава бассейнының, туфрак катламының пычрануын булдырмау һәм киметүнең барлык техник һәм технологик мөмкинлекләрен ачыклау һәм алардан файдалану.

Эшләр башкарганда җирләрне саклау өчен проект чишелешләре:

- җирләрдән нәтиҗәле файдалану;

- төзелеш участогы чикләрен төгәл үтәү;

- туфракның уңдырышлы катламын алу, саклау һәм вакытында файдалану нормаларын үтәү;

- ягулык-майлау материалларын грунтка агызуны булдырмау;

- төзелеш чүп-чарларын вакытында җыюны һәм чыгаруны оештыру, аннары утильләштерү;

